КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 27 июль г.Казань № 722

2022 елда территорияне планлаштыру проектларын, территорияне межалау проектларын раслау һәм әлеге проектларга, җәмәгатьчелек фикер алышуларын яки ачык тыңлаулар үткәрмичә, үзгәрешләр кертү очракларын билгеләү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 мартындагы 58-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

2022 елда Татарстан Республикасы территориясендә түбәндәгеләрне билгеләргә:

территорияне планлаштыру проектларын, территорияне межалау проектларын раслау түбәндәге очракларда җәмәгатьчелек фикер алышуларын яки ачык тыңлаулар үткәрмичә гамәлгә ашырыла:

җирле әһәмияттәге социаль инфраструктура объектлары урнаштырылганда,

җирле әһәмияттәге линия объектлары урнаштырылганда,

бу территория чикләрендә башка хокук ияләренә караган җир кишәрлекләре (дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җир кишәрлекләреннән, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләреннән һәм җирләрдән тыш) булмау шарты белән межалау проекты эшләнгән территория чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренең хокук ияләре тарафыннан территорияне межалау проектлары әзерләнгәндә;

территорияне планлаштыру проектларына, территорияне межалау проектларына үзгәрешләр кертү, әлеге проектларга аларның аерым өлешләрен раслау юлы белән үзгәрешләр кертелгән очракта, җәмәгатьчелек фикер алышуларын яки ачык тыңлаулар үткәрмичә гамәлгә ашырыла;

әгәр бу карар үз көченә кергән көндә тиешле җәмәгатьчелек фикер алышуларын яки ачык тыңлаулар үткәрү турында белдерү бастырып чыгарылган булса, мондый җәмәгатьчелек фикер алышуларын яки ачык тыңлаулар законнар белән билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин